Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Ямаши авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

20 октября 2022 ел №14

Әлмәт муниципаль районы Ямаши авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрьдәге 12 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Ямаши авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгын куркынычсызлыгы турында»1994 елның 18 ноябрендәге 719 номерлы карары нигезендә

Ямаши авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Ямаши авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрдәге 12 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Ямаши авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

I бүлекнең 3 пункты тугызынчы абзацында «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү проблемалары һәм юллары турында максатчан мәгълүмат бирү,» сүзләрен «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү юллары турында хәбәр итү,» сүзләренә, «җайланма» сүзен «уздыру» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Ямаши авылы Совет урамы, 4 нче йорт; Рокашево авылы, Үзәк урам, 1 нче йорт; Красная Горка авылы, Тихая Аллея урамы, 9 нчы йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Ямаши авылы башкарма
комитеты җитәкчесе А.А. Андревкина